**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 18 июнь № 412

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү күпфункциональ үзәкләре базасында күрсәтелә торган дәүләт, муниципаль һәм башка хезмәтләрнең якынча исемлеге турында» 2012 ел, 21 июнь, 539 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасының дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү күпфункциональ үзәкләре базасында күрсәтелә торган дәүләт, муниципаль һәм башка хезмәтләрнең якынча исемлегенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү күпфункциональ үзәкләре базасында күрсәтелә торган дәүләт, муниципаль һәм башка хезмәтләрнең якынча исемлеге турында» 2012 ел, 21 июнь, 539 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 2 октябрь, 713 нче; 2014 ел, 26 март, 187 нче; 2014 ел, 24 декабрь, 1020 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү күпфункциональ үзәкләре базасында күрсәтелә торган дәүләт, муниципаль һәм башка хезмәтләрнең якынча исемлегенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

I бүлектә:

«Дәүләт учреждениесе – Россия Федерациясе Социаль иминият фондының Татарстан Республикасы буенча төбәк бүлеге» бүлекчәсен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| «Россия Федерациясе Социаль иминият фондының Татарстан Республикасы буенча төбәк бүлеге дәүләт учреждениесе» | |
|---|---|
| 1. | Иминият кертемнәрен исәпләү һәм түләү (күчерү) өчен нигез булган документларны, шулай ук иминият кертемнәрен исәпләүнең дөреслеген һәм түләүнең (күчерүнең) үз вакытында булуын раслый торган документларны кабул итү |
| 2. | Вакытлыча эшкә яраксызлык очрагында һәм ана булу белән бәйле мәҗбүри социаль иминиятләү буенча ирекле рәвештә хокукый мөнәсәбәтләргә кергән затларны теркәү һәм теркәү исәбеннән төшерү |
| 3. | Хезмәткәр белән хезмәт шартнамәсе төзегән физик затларны иминиятләүчеләрне теркәү һәм теркәү исәбеннән төшерү |
| 4. | Иминиятләүчеләрне – граждан-хокукый шартнамәләре төзү белән бәйле иминият кертемнәре түләргә тиешле физик затларны теркәү һәм теркәү исәбеннән төшерү |
| 5. | Инвалидларны техник тернәкләндерү чаралары һәм (яки) хезмәт күрсәтүләр һәм ветераннар арасыннан гражданнарның аерым категорияләрен протезлар (теш протезларыннан тыш), протез-ортопедия эшләнмәләре белән тәэмин итү, шулай ук инвалидлар үзләре сатып алган техник тернәкләндерү чаралары (ветераннар тарафыннан протезлар (теш протезларыннан тыш) (яки) түләнгән хезмәт күрсәтүләр өчен компенсация һәм инвалидларның озатып йөрүче этләрне карап тоту һәм ветеринария хезмәте күрсәткән өчен чыгымнарына еллык акчалата компенсация түләү |
| 6. | Россия Федерациясе Социаль иминият фонды социаль хезмәт күрсәтү җыелмасы рәвешендә дәүләт социаль ярдәмен алырга хокуклы гражданнарга медицина күрсәткечләре булганда төп авырулары профилактикасы максатларында гамәлгә ашырыла торган шифаханә-курорт дәвалавына юлламалар һәм шәһәрара транспортта дәвалау урынына бару һәм кире кайту өчен бушлай юл йөрү хокукы бирә»; |

«Дәүләт мөлкәте белән идарә итү федераль агентлыгының Татарстан Республикасында территориаль идарәсе» бүлекчәсен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| «Дәүләт мөлкәте белән идарә итү федераль агентлыгының Татарстан Республикасында территориаль идарәсе | |
|---|---|
| 1. | Федераль милектәге җир кишәрлеге бирүне башлангыч килештерү |
| 2. | Федераль милектәге җир кишәрлекләрен сатулар үткәрмичә бирү |
| 3. | Федераль милектәге җир кишәрлекләрен сатуларда бирү |
| 4. | Федераль мөлкәт реестрыннан билгеләнгән тәртиптә өземтәләр бирүне гамәлгә ашыру»; |

II бүлектә:

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Баш архив

идарәсе» бүлекчәсе исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты»;

түбәндәге эчтәлекле «V. Эшмәкәрлек субъектларына дәүләт, муниципаль, өстәмә (иярчен) хезмәтләр күрсәтүгә ориентлашкан дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкләр хезмәтләре» бүлекчәсен өстәргә:

| | |
|---|---|
| «V. Эшмәкәрлек субъектларына дәүләт, муниципаль, өстәмә (иярчен) хезмәтләр күрсәтүгә ориентлашкан дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкләр хезмәтләре | |
| Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе | |
| 1. | Күчемсез милеккә һәм аның белән алыш-бирешләргә хокукларны дәүләт теркәве |
| 2. | Күчемсез милеккә һәм аның белән алыш-бирешләргә хокукларның бердәм дәүләт реестрындагы мәгълүматларны бирү (физик һәм юридик затлар соратуы буенча әлеге реестрдан өземтәләр бирү өлешендә) |
| «Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Федераль кадастр палатасы» федераль дәүләт бюджет учреждениесенең Татарстан Республикасы буенча филиалы | |
| 1. | Күчемсез милекнең дәүләт кадастр исәбе |
| 2. | Күчемсез милекнең дәүләт кадастрындагы мәгълүматларны бирү (физик һәм юридик затлар соратуы буенча әлеге кадастрдан өземтәләр бирү өлешендә) |
| Татарстан Республикасы буенча эчке эшләр министрлыгы | |
| 1. | Юл хәрәкәте өлкәсендә административ хокук бозулар турында мәгълүматлар бирү |
| Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе | |
| 1. | Юридик затларны, физик затларны шәхси эшмәкәрләр һәм крестьян (фермер) хуҗалыклары буларак дәүләт теркәвенә алу |
| 2. | Салым түләүчеләргә, җыемнар түләүчеләргә һәм салым агентларына гамәлдәге салымнар һәм җыемнар, Россия Федерациясенең салымнар һәм җыемнар турындагы законнары һәм алар нигезендә кабул ителгән норматив хокук актлары, салымнарны һәм җыемнарны исәпләү һәм түләү тәртибе, салым түләүчеләрнең, җыемнар түләүчеләрнең һәм салым агентларының хокуклары һәм бурычлары, салым органнарының һәм аларның вазыйфаи затларының вәкаләтләре хакында бушлай мәгълүмат бирү (шул исәптән язма рәвештә) |
| 3. | Дисквалификацияләнгән затлар реестрындагы мәгълүматларны бирү |
| 4. | Салым түләүчеләрнең бердәм дәүләт реестрындагы мәгълүматларны бирү (салым серен үз эченә алган мәгълүматлардан тыш, физик затлар һәм юридик затлар сораулары буенча әлеге реестрдан чыгармалар бирү өлешендә) |
| 5. | Юридик затларның бердәм дәүләт реестрындагы һәм Шәхси эшмәкәрләрнең |

| | |
|---|---|
| | бердәм дәүләт реестрындагы мәгълүматларны бирү (физик затлар һәм юридик затлар сораулары буенча әлеге реестрлардан чыгармалар бирү өлешендә, файдаланылу мөмкинлекләре чикләнгән мәгълүматларны үз эченә алган чыгармалардан тыш) |
| 6. | Салым түләүченең (җыемнар түләүченең, салым агентының) салымнар, җыемнар, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча йөкләмәләрен үтәве турында белешмә кәгазе бирү хакындагы соравын кабул итү |
| Россия Федерациясе Пенсия фондының Татарстан Республикасы буенча бүлеге | |
| 1. | Иминият кертемнәрен түләүчеләргә Россия Федерациясенең иминият кертемнәре турындагы законнары һәм алар нигезендә кабул ителгән норматив хокук актлары, иминият кертемнәрен исәпләү һәм түләү тәртибе, Россия Федерациясе Пенсия фонды, Россия Федерациясе Пенсия фондының территориаль органнары һәм аларның вәкаләтләре һәм вазыйфаи затлары турында түләүсез мәгълүмат бирү, шулай ук исәпләнгән һәм түләнгән иминият кертемнәре буенча исәп-хисаплар формаларын кертү һәм, мөрәҗәгать язмача кертелгән очракта, аларны тутыру тәртибен аңлату |
| Суд приставлары федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе | |
| 1. | Физик һәм юридик затларга карата үтәү производствосы тарафыннан үтәүдә булган мәгълүмат бирү |
| «Россия Федерациясе Социаль иминият фондының Татарстан Республикасы буенча төбәк бүлеге дәүләт учреждениесе | |
| 1. | Иминият кертемнәрен исәпләү һәм түләү (күчерү) өчен нигез булган документларны, шулай ук иминият кертемнәрен исәпләүнең дөреслеген һәм түләүнең (күчерүнең) үз вакытында булуын раслый торагын документларны кабул итү |
| 2. | Вакытлыча эшкә яраксызлык очрагында һәм ана булу белән бәйле мәҗбүри социаль иминиятләү буенча ирекле рәвештә хокукый мөнәсәбәтләргә кергән затларны теркәү һәм теркәү исәбеннән төшерү |
| 3. | Хезмәткәр белән хезмәт шартнамәсе төзегән физик затларны иминиятләүчеләрне теркәү һәм теркәү исәбеннән төшерү |
| 4. | Иминиятләүчеләрне – граждан-хокукый шартнамәләре төзү белән бәйле иминият кертемнәре түләргә тиешле физик затларны теркәү һәм теркәү исәбеннән төшерү |
| Татарстан Республикасында Дәүләт хезмәт инспекциясе | |
| 1. | Эш бирүчеләргә һәм хезмәткәрләргә хезмәт турындагы законнарны һәм хезмәт хокукы нормаларын үз эченә алган башка норматив хокук актларын үтәү мәсьәләләре турында мәгълүмат бирү |
| 2. | Юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр тарафыннан индивидуаль саклану чаралары җитештерү эшчәнлегенең аерым төрләре гамәлгә ашырыла башлау турында хәбәрнамәләр кабул итү һәм аларны исәпкә алу |

| | |
|---|---|
| Дәүләт мөлкәте белән идарә итү федераль агентлыгының Татарстан Республикасындагы территориаль идарәсе | |
| 1. | Федераль милектәге җир кишәрлеген бирүне башлангыч килештерү |
| 2. | Федераль милектәге җир кишәрлекләрен сатулар үткәрмичә бирү |
| 3. | Федераль милектәге җир кишәрлекләрен сатуларда бирү |
| 4. | Федераль мөлкәт реестрыннан билгеләнгән тәртиптә өземтәләр бирүне гамәлгә ашыру |
| Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеген саклау өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе | |
| 1. | Юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр тарафыннан Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Эшмәкәрлек эшчәнлегенең аерым төрләрен гамәлгә ашыра башлауның хәбәр итү тәртибе турында» 2009 ел, 16 июль, 584 нче карары белән расланган Эшмәкәрлек эшчәнлегенең аерым төрләрен гамәлгә ашыра башлау турында хәбәрнамәләр кертү һәм әлеге хәбәрнамәләрне исәпкә алу кагыйдәләренә теркәлгән исемлектә күрсәтелгән эшләрнең һәм хезмәт күрсәтүләрнең аерым төрләре гамәлгә ашырыла башлау хакында хәбәрнамә кабул итүне һәм аны исәпкә алуны тормышка ашыру». |

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков